# ХӘБӘРЧЕ 34

безгә 1976 елдан ышаналар

выпуск #7

Бу номерда:

- халкым үрнәкләре: сөлге чигү
- сабын ясау серләре
- күпмилләтле республикам минем
- мәктәп йолдызлары



MADE IN TATARSTAN

# ХАЛКЫМ ҮРНӘКЛӘРЕ: СӨЛГЕ ЧИГҮ



Алсу укытучысы Наталия Сергеевна белән



Гасырлардан гасырларга килә,
Халкыбызның гореф-гадәте.
Чал тарихлы олуг мирасыбыз-
Бизәү төре - чигү сәнгате.


Татар халкы һәрвакыт матурлыкка омтылып яшәгән. Күп гасырлык тарихны сыйдырган милли киемнәр дә – татар халкының үткәнен бүгенгесе белән тоташтыручы байлык. Алар әби-бабаларыбызның йөзен чагылдыручы асылташлар булып балкый. Энҗе-мәрҗән белән чигелгән укалы калфак, бала итәкле күлмәк, тамбур белән чуп- ләмләп чигелгән алъяпкыч бүгенге көндә дә тиңсез хәзинә. Бу бизәкләргә халкымның күңел җылысы салынган.

Мин сәнгать мәктәбенә йөри башлагач ук, бу сәнгать төре мине үзенә җәлеп итте. Дәрестә без күп рәсемнәр ясыйбыз, сөлгеләр чигәбез. Әлеге сөлгене мин дәрестә укытучы белән бергә чигә башлаган идем. Укытучы ярдәме, киңәшләре белән бизәк, минемчә, бик матур килеп чыкты. Бу – тамбур чигүе дип атала.

Кем бу төр сәнгать белән кызыксына, аларга берничә киңәшем бар: беренчедән, сурәтне башта кәгазьдә ясарга кирәк; икенчедән, тукыманы дөрес сайларга; өченчедән, төсләрне дөрес сайлау да бик мөһим.

Кул шомарганчы шактый вакыт кирәк. Бу шөгыль күп сабырлык сорый. Сөлгене 1 ай чиктем. Миңа хәтта әнием дә булышты, чөнки анда да кызыксыну артты.

"Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк", – ди халык мәкале. Ә халык әйтсә, хак әйтә. Шуны истә тотып, халкыбызның үзенчәлекле чигү төрләрен барлауны һәм бүгенге көндә чигүче милләттәшләремнең кул эшләре белән танышуны мөһим дип саныйм.



Тамбур чигүнең төрләре: төенчекле һәм элмәкле

Автор һәм кул остасы
**Зиннәтуллина Алсу,**
7 нче Б сыйныфы укучысы





# САБЫН ЯСАУ СЕРЛӘРЕ

5 нче В сыйныфында укучы Захурдаева Настя өй шартларында әнисе белән бернечә ел инде сабын ясау белән мавыга.



Сабынны башта әнисе ясап караган. Аннан соң алар икәүләшеп ясарга уйлаганнар. Алар әйтүенчә, сабын ясауның үзенчәлекләре бар икән.

Әйтик, аны кайнар һәм салкын ысул белән дә ясарга мөмкин. Әмма мондый очракта сыйфаты да аерылып тора.

Кибет сабыны бик тиз күбекләнә, чөнки аларга махсус матдәләр кушалар. Ә аларның сабыннарында андый матдәләр юк, шуңа күрә күбрәк ышкырга кирәк, диләр алар. Кулдан ясалган сабыннар формасы белән дә, сыйфаты белән дә аерыла. Алар сабынга бернечә төрле май да кушалар икән.

Сабыннарга заказ бирүчеләр күп, диләр алар, хәтта зур торт рәвешендәге сабыннар да сорыйлар.

Өй шартларында сабын ясау бик мавыктыргыч шөгыль, чөнки үз кулларың белән ясалган әйберне күреп, аны көнкүрештә куллану, якыннарыңа бүләк итү бик күңелле шул.







# МӘКТӘП ЙОЛДЫЗЛАРЫ



## БАШИРОВА АГАТА

11 нче сыйныф укучысы – безнең сәләтле кызларыбызның берсе. Яхшы укый, буш вакытында гитарада уйный. Дус-ишләре арасында үз кеше...

**– Агата, гитарада үзлегеңнән уйнарга өйрәндеңме?**

– Юк, безнең мәктәптә бит музыка мәктәбенең филиалы эшли. Мин кызыксынып кына шунда барып карадым, гитарада уйнау миңа бик зур тәэсир ясады. Миндә гитарада уйнау теләге туды. Инде остарып та життем (*көлә*). Музыка укытучысы Тэна Васильевна миңа үз-үземне сынап карарга киңәш бирде. “Жыр, гитара һәм мин” дигән бәйгедә катнашырга теләк белдердем. В.Цойның “Соңгы герой” исемле жыры белән чыгыш ясадым. Кызганыч, беренче елны финалга да чыкмадым.

**– Күңелең төштеме?**

– Юк, үз-үземне тынычландырдым да, тагын бер бәхетемне сынап карарга теләк белдердем. Озак әзерләндем. Үз алдыма куелган максатка ирешәсем килде. 2021 елның декабрендә 2 нче урын алдым. Бу минем өчен зур бәхет булды.

**– Агата, без сине чын күңелебездән котлыйбыз! 2022 елга нинди планнарың бар?**

– Иң беренче чиратта, имтиханнарымны яхшы билгеләргә генә тапшырасым килә.

**– Уңышлар сиңа, Агата!**

Әңгәмәдәш **Камилә Исхакова**,
Агатаның сыйныфташы.








## КОМАРОВА МАРИЯ

6 нчы В сыйныфы укучысы. Оптимист, бик сәләтле кыз. Иждади бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннарга ия булган йолдызыбыз.

«Фәнни-практик конференцияләр, дөресен әйткәндә, мине куркуга сала иде. Ничек итеп тема сайларга, бу теманы ничек ачарга, комиссия әһелләре алдында ничек чыгыш ясарга дигән сораулар мине гел туктатып торды.

Ә менә Нурия Рашидовна «Фәнгә беренче адым» дигән XXVIII Бөтенроссия балалар фәнни-практик конкурсында катнашырга тәкъдим иткәч, мин ризалык бирдем. «Краеведение» юнәлеше мине кызыксындырды, чөнки әнием-нең туган ягына кайткан саен авылның тарихы мине җәлеп итеп торды. Аның табигатенең матурлыгын, тарихи урыннарын, бу авылның оешу тарихын башкаларга да җиткерәсем килде. Шулай итеп, Кайбыч районында урнашкан Турмин авылының тарихын фәнни яктан нигезләп эшкә керештем.

«Турмин авылының бүгенгесе һәм киләчәге» дип аталган эшемне Мәскәүгә җибәрдек. Заочный турда призлы урын яуладым һәм Мәскәүгә очный турга чакыру килде. 2021 елның декабрендә Мәскәүдә фәнни конференциядә чыгыш ясау бәхете насыйп булды. 15 кешелек төркемдә мин Лауреат исемен алдым. Диплом һәм истәлекле бүләкләргә лаек булдым. Мин бәхетле, чөнки кечкенә генә, ләкин зур тарихы булган авыл турында сөйли алдым.»

Тәрҗемәче **Әхмәдуллина Әмирә**,
6 нчы А сыйныфы укучысы



Маша тәбрикләү тантанасында

# КҮПМИЛЛӘТЛЕ РЕСПУБЛИКАМ МИНЕМ!







Шартова Карина, Шайдулова Диана, Зуева Кира 3 нче В сыйныфы
Тешаева  Әмина, Шаймарданова Асель 3 нче А сыйныфы

# ТАМЧЫ-ШОУ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ



Ел саен безнең мәктәп укучылары Шаян ТВ каналында оештырыла торган фәнни-интеллектуаль «Тамчы-шоу» бәйгесендә зирәклектә һәм тапкырлыкта көч сынашалар. Быел да 6 нчы сыйныф укучылары Гәрәева Алинә, Мингалиева Зәйнәп һәм Сәгъдиев Зөфәр үзләренең осталыкларын, белемнәрен күрсәттеләр. Бәйге бик тә истә калырлык булды, чөнки кунакка ерак Үзбәкстаннан кунаклар килгән иде. Профессор Ә.Н.Хузиахметов укучыларга уңышлар теләп бәйгене ачып җибәрде. Ә ахырда укучыларга Г.Камал театрына билетлар бүләк иттеләр.

Укучылар театрга барып, вакытларын күңелле һәм файдалы итеп уздырдылар.



Укучылар елдагыча бәйгегә бик тырышып әзерләнделәр. Сораулар авыр да, эзләнерлек тә, уйланырлык та булды. Һәрвакыттагыча инстаграм сораулары укучыларны аптырашта калдырды...





# ӘДҺӘМОВА КАМИЛӘ





Мин Сәнгать(дөнья сәнгать мәдәнияте) буенча олимпиадага беренче тапкыр бардым. Анда биремнәр музыка, кино, рәсем һәм мигъмарият буенча булды. Соңгы биремдә бер фильмнан кадр күрсәтелгән иде, безгә исемен язарга кирәк булды. Күргәнегезчә, биремнәр җиңел түгел.

2022 елда олимпиада биремнәренә тагын бер яңалык өстәлгән. Ул да булса - диктант язу.

Мин олимпиадага үзем генә бармадым, 11 нче сыйныфтан Александра (газетаның рәссамы - ред. өстәмәсе) белән бардым. Без аның белән бергә әзерләндек: Мәскәү, Италия һәм Санкт-Петербург мигъмариятен карадык. Сашаның биремнәре дә, диктанты да авыррак булды. Мигъмарият буенча биремнәр охшаш иде: минем биремдә «Кышкы сарай» һәм «Петр I җәйге сарае» булды, ә Сашада Мәскәү вокзалы күрсәтелгән иде.

Бу олимпиада миндә бик күп яңа белемнәр, эмоцияләр калдырды. Алар мине уйларга мәҗбүр итте, үземне иҗади яктан күрсәтергә мөмкинлек бирде.

Ә музыка ягыннан бөек уңышлар өчен 2021 елда мине Казан шәһәре Мэры Ильсур Рәисович үзенең исемле стипендия белән бүләкләде.





# ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕНӘ ИЯРЕП..



## ...ӘКИЯТ СӨЙЛИМ СЕЗГӘ

Борын-борын заманда, ә бәлки безнең заманда, җир йөзендә бик матур да, тәртипле дә, эшчән дә булган кешеләр яшәгән. Алар һәрвакыт шат, таза булганнар, илләре гөлбакчага тиң булган. Ләкин аларга нидер булган: яшел үләндә генә яланаяк йөрү, саф чишмә суы, калын-калын урманнар гына җитмәгән. Яшел үлән өстенә таш җәйгәннәр, чишмә суларын каплап, краннарга тоташтырганнар, тимер кошлар да һавага ук күтәрелә башлаганнар. Табигать әкренләп боеккан, юкка чыккан. Кешеләргә бик авыр кайгы килгән: алар үлә башлаганнар. Яшь балалар да, таза, көчле ир-егетләр дә, картлар да кырыла гына икән. Халык бу афәттән ничек тә котылырга белмәгәннәр.

Бу вакытта кешеләр арасында бик акыллы егет яшәгән икән. Ул халыкны бу кайгыдан араларга теләгән. Ата-анасының фатихасын алган да терелтә ала торган үләннәр эзләп чыгып киткән. Бик озак йөргән ди ул. Бер генә файда китерә ала торган үләннәр дә тапмаган. Шулай йөри торгач, ул бер кара урманга килеп чыккан. Бу урман иясенең патшалыгы икән. Егет бер матур сарай күргән һәм шул сарайга карап туры юл тоткан. Аны анда бик карт кына карчык каршы алган. Бу – урман карчыгы икән. Ул егеткә:





– Тиз генә кит моннан. Югыйсә, мин сине юк итәчәкмен,– ди икән.

Егет үзенең нинди эш белән йөрүен сөйләгән:

– Менә сез матур, куе урманда яшисез. Тирә-ягыгыз матур чәчәкләр, тәмле җиләк-җимешләр белән тулган. Тәмле сулы чишмәләрегез челтерәп агып ята. Саф һавадан башлар әйләнә – дигән егет. – Мин дә үз халкыма шушындый матурлыкны бирәсем, аларны авырудан коткарасым килә, дигән.

Карчык егетне тыңлап торган да әйткән:

– Кайчандыр сезнең илегез дә шундый ук матур иде. Кызганыч, сез үзегез табигатьне үтердегез. Инде үзегез дә юкка чыгу алдында торасыз. Сезне инде бер генә нәрсә коткара ала, ул да булса, табигатьне яшәртү.

Егет бик үтенгәч, серне чишкән. Бер чишмә янына алып килгән. Чишмәнең тирә-ягы яшел үләннәр, матур чәчәкләр белән бизәлгән, агачларда кошлар сайрый икән. Бу тереклек чишмәсе була. Егет савытын тутырып су ала да, карчык белән саубуллашып, юлга чыга.

Кайткач та, карчык өйрәткәнчә, җирне чүп-чардан чистарта. Моны карап торучылар башта ышанмыйлар, ә соңрак әкрен генә ярдәм итә башлыйлар. Аларга башта һәр хәрәкәт авыр бирелә, ә соңрак үзләрендә көч артуын тоялар. Җирне яңадан сукалап, яшь агачлар, чәчәкләр утырталар, үлән чәчәләр. Ә егет тимер кошта соңгы мәртәбә күккә күтәрелә һәм тереклек суын Җиргә сибә. Бар тереклек яшәреп, үсеп китә. Кешеләр дә киң итеп сулыш ала башлыйлар, авырулары да юкка чыга. Шуннан со илләренә тимер кошлар да кертмиләр, таш юллар да салмыйлар. Табигать белән бер җан булып яши башлыйлар.

**Гарипова Алзирә,**
6А сыйныфы укучысы;

рәсем авторы
**Рябова Александра**
11А сыйныфы укучысы

## 34KAZANSCHOOLMEDIA ТАТАР РЕДАКЦИЯСЕ:

**Авторлар**:
Зиннатуллина Алсу
Нечаева Карина
Белова Анастасия
Исхакова Камиля
Хасанова Азалия
Зиннатуллина Рената
Гарипова Алзира
Ахмадуллина Амира

**Дизайн**:
Рябова Александра

**Корректор**:
Адгамова Камиля

**Редакторлар:**
Березкина Гульназ Талгатовна
Галимова Ильмира Гайсовна

**Верстка**:
Загидуллин Рамиль Маратович

**Шеф-редактор:**
Гимадеева Нурия Рашидовна

**Директор**:
Насыбуллина Лилия Анваровна

**Редакция адресы:**
420066, Короленко ур., 26
34KazanSchoolMedia татар
редакциясе

**Вакытлылык**:
айга 1 мәртәбә

**Тираж**:
50 экземпляр

**Дата**:
февраль 2022